**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 15 ноябре** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Ләшәү Тамак авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан; өлкән, ялгыз яшәүче затлардан; Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
1) Ләшәү Тамак авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү)
2) Ләшәү Тамак авылында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);
3)юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);
4) Ләшәү Тамак авылы, Ленин урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);

3. Әлеге карарны Ләшәү Тамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.З.Хабибуллин